КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 1170

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1071 нче карары белән расланган «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1071 нче карары белән расланган «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары ярдәмчесе Алексей Константинович Кирпичниковны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә караган торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге баш киңәшчесе Айдар Ринат улы Кашаповны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә караган юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру бүлеге баш киңәшчесе Айгөл Илгиз кызы Трофимованы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин